| | раслаучы документ;<br>11) Россия Федерациясе Һава кодексының 131 статьясы нигезендә өченче затлар каршында һава судносы хуҗасының җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерүне раслаучы документлар;<br>12) гаризаны имзалаган затның вәкаләтләрен раслаучы документ.<br>2.5.3.2. парашютта сикерүләрне башкаруга:<br>1) һава судносының тибын, дәүләт (теркәү) тану билгесен, завод номерын (булган очракта) һәм кемнеке булуын, авиация эшчәнлеген башкару чорын һәм урынын күрсәтеп, регламентка 1 нче кушымтада каралган форма буенча төзелгән гариза;<br>2) юридик зат уставы, әгәр гариза бирүче булып юридик зат торса;<br>3) әгәр гариза бирүче булып физик зат/шәхси эшмәкәр торса, гамәлдәге законнар нигезендә шәхесне таныклаучы документ;<br>4) билгеләнгән һава судносының эксплуатацияләүгә яраклылыгын раслаучы документ (һава судносы формулярыннан эксплуатацияләүгә яраклылык турында язылган өземтә);<br>5) һава судолары командирларын очышларга кертү турында приказ;<br>6) гариза бирүченең базасында Парашют-десант хезмәтен оештыру турында нигезләмә;<br>7) Россия Федерациясе Һава кодексы яки әлеге шартнамәләргә карата полислар (сертификатлар) күчермәләре нигезендә мәҗбүри иминият шартнамәсе;<br>8) һава судносының күтәрелү вакытын, урынын, биеклеген һәм санын күрсәтеп, парашютчыларны десантлау тәртибе проекты;<br>9) һава судносын теркәү турында мәгълүматлар БДХРда булмаган очракта, һава судносына хокук | |

| | | |
|---|---|---|
| | билгели торган документ. Әгәр һава судносы өлешле милектә булса – барлык милекчеләрнең дә гариза бирүче тарафыннан һава судносыннан файдалануга ризалыгын раслаучы документ;<br>10) Россия Федерациясе Һава кодексының 131 статьясы нигезендә өченче затлар каршында һава судносы хуҗасының җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерүне раслаучы документлар;<br>11) гаризаны имзалаган затның вәкаләтләрен раслаучы документ.<br>2.5.3.3. Яр Чаллы шәһәре өстендә бәйләп куела торган аэростатларны күтәрүне башкаруга:<br>1) һава судносының тибын, дәүләт (теркәү) тану билгесен, завод номерын (булган очракта) һәм кемнеке булуын, авиация эшчәнлеген башкару чорын һәм урынын күрсәтеп, регламентка 1 нче кушымтада каралган форма буенча төзелгән гариза;<br>2) юридик зат уставы, әгәр гариза бирүче булып юридик зат торса;<br>3) әгәр гариза бирүче булып физик зат/шәхси эшмәкәр торса, гамәлдәге законнар нигезендә шәхесне таныклаучы документ;<br>4) билгеләнгән һава судносының эксплуатацияләүгә яраклылыгын раслаучы документ (һава судносы формулярыннан эксплуатацияләүгә яраклылык турында язылган өземтә);<br>5) һава судноларының командирларын очышларга кертү турында приказ;<br>6) Россия Федерациясе Һава кодексы яки әлеге шартнамәләргә карата полислар (сертификатлар) күчермәләре нигезендә мәҗбүри иминият шартнамәсе;<br>7) 50 метрдан югарыга күтәрү гамәлгә ашырылган очракта, бәйләп куела торган аэростатларны күтәрү вакытын, урынын, биеклеген | |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтеп, бәйләп куела торган аэростатларны күтәрүне башкару тәртибе проекты;<br>8) Россия Федерациясе Һава кодексының 131 статьясы нигезендә өченче затлар каршында һава судносы хуҗасының җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерүне раслаучы документлар;<br>9) һава судносын теркәү турында мәгълүматлар БДХРда булмаган очракта, һава судносына хокук билгели торган документ. Әгәр һава судносы өлешле милектә булса – барлык милекчеләрнең дә гариза бирүче тарафыннан һава судносыннан файдалануга ризалыгын раслаучы документ;<br>10) гаризаны имзалаган затның вәкаләтләрен раслаучы документ.<br>2.5.3.4. һава судноларының демонстрацион очышларын башкаруга:<br>1) һава судносының тибын, дәүләт (теркәү) тану билгесен, завод номерын (булган очракта) һәм кемнеке булуын, авиация эшчәнлеген башкару чорын һәм урынын күрсәтеп, регламентка 1 нче кушымтада каралган форма буенча төзелгән гариза;<br>2) юридик зат уставы, әгәр гариза бирүче булып юридик зат торса;<br>3) әгәр гариза бирүче булып физик зат/шәхси эшмәкәр торса, гамәлдәге законнар нигезендә шәхесне таныклаучы документ;<br>4) Россия Федерациясе Һава кодексы яки әлеге шартнамәләргә карата полислар (сертификатлар) күчермәләре нигезендә мәҗбүри иминият шартнамәсе;<br>5) түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган демонстрацион очышларны башкару тәртибе проекты:<br>а) һава судносының тибы;<br>б) һава судносы очышының максаты һәм кемнеке булуы; | |

| | | |
|---|---|---|
| | в) төшү мәйданчыгы;<br>г) очып китү-төшү вакыты;<br>д) очу маршруты һәм (яки) районы;<br>е) очу биеклеге;<br>ж) һава хәрәкәтенә хезмәт күрсәтү тәртибе;<br>6) һава судносын теркәү турында мәгълүматлар БДХРда булмаган очракта, һава судносына хокук билгели торган документ. Әгәр һава судносы өлешле милектә булса – барлык милекчеләрнең дә гариза бирүче тарафыннан һава судносыннан файдалануга ризалыгын раслаучы документ;<br>7) Россия Федерациясе Һава кодексының 131 статьясы нигезендә өченче затлар каршында һава судносы хуҗасының җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерүне раслаучы документлар;<br>8) гаризаны имзалаган затның вәкаләтләрен раслаучы документ.<br>2.5.3.5. алар хакында белешмәләр аэронавигация мәгълүматлары документларында күрсәтелмәгән Яр Чаллы шәһәре чикләрендә урнашкан мәйданчыкларга төшүгә (очып китүгә):<br>1) һава судносының тибын, дәүләт (теркәү) тану билгесен, завод номерын (булган очракта) һәм кемнеке булуын, авиация эшчәнлеген башкару чорын һәм урынын күрсәтеп, регламентка 1 нче кушымтада каралган форма буенча төзелгән гариза;<br>2) юридик зат уставы, әгәр гариза бирүче булып юридик зат торса;<br>3) әгәр гариза бирүче булып физик зат/шәхси эшмәкәр торса, гамәлдәге законнар нигезендә шәхесне таныклаучы документ;<br>4) Россия Федерациясе Һава кодексы яки әлеге шартнамәләргә карата полислар (сертификатлар) күчермәләре нигезендә мәҗбүри иминият шартнамәсе; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 5) мәйданчыкның урнашу урыны, очыш вакыты, биеклеге, төшү (очып китү) урынына килү һәм китү маршруты турында мәгълүматлар;<br>6) һава судносын теркәү турында мәгълүматлар БДХРда булмаган очракта, һава судносына хокук билгели торган документ. Әгәр һава судносы өлешле милектә булса – барлык милекчеләрнең дә гариза бирүче тарафыннан һава судносыннан файдалануга ризалыгын раслаучы документ;<br>7) Россия Федерациясе Һава кодексының 131 статьясы нигезендә өченче затлар каршында һава судносы хуҗасының җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерүне раслаучы документлар;<br>8) гариза язган затның вәкаләтләрен раслаучы документ.<br>2.5.3.6. пилотсыз һава суднолары очышларын башкаруга (максималь очыш массасы 0,25 кг ким булган пилотсыз һава суднолары очышларыннан тыш):<br>1) һава судносының тибын, дәүләт (теркәү) тану билгесен, завод номерын (булган очракта) һәм кемнеке булуын, авиация эшчәнлеген башкару чорын һәм урынын күрсәтеп, регламентка 1 нче кушымтада каралган форма буенча төзелгән гариза,;<br>2) юридик зат уставы, әгәр гариза бирүче булып юридик зат торса;<br>3) әгәр гариза бирүче булып физик зат/шәхси эшмәкәр торса, гамәлдәге законнар нигезендә шәхесне таныклаучы документ;<br>4) Россия Федерациясе Һава кодексы яки әлеге шартнамәләргә карата полислар (сертификатлар) күчермәләре нигезендә мәҗбүри иминият шартнамәсе;<br>5) һава судносының техник характеристикаларын раслаучы документ (һава судносының максималь очып китү массасы | |

| | | |
|---|---|---|
| | (конструкция массасы) күрсәтелгән паспорты яки файдаланучы өчен кулланма);<br>6) түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган пилотсыз һава судносы очышын башкару тәртибе проекты:<br>а) пилотсыз һава судносының тибы;<br>б) пилотсыз һава судносы очышының максаты һәм кемнеке булуы;<br>в) төшү мәйданчыгы;<br>г) очып китү-төшү вакыты;<br>д) очу маршруты һәм (яки) районы;<br>е) очу биеклеге;<br>7) A, C һәм G класслы һава киңлегендә пилотсыз очу аппаратын куллануга рөхсәт алган очракта – һава судносының очыш планы;<br>8) һава судносын теркәү турында мәгълүматлар БДХРда булмаган очракта, һава судносына хокук билгели торган документ. Әгәр һава судносы өлешле милектә булса – барлык милекчеләрнең дә гариза бирүче тарафыннан һава судносыннан файдалануга ризалыгын раслаучы документ;<br>9) Россия Федерациясе Һава кодексының 131 статьясы нигезендә өченче затлар каршында һава судносы хуҗасының җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерүне раслаучы документлар;<br>10) гаризаны имзалаган затның вәкаләтләрен раслаучы документ.<br>A, C һәм G класслы һава киңлегендә пилотсыз һава судносы белән һава киңлегеннән файдалану һава судносының очу планы һәм һава киңлегеннән файдалануга рөхсәт нигезендә гамәлгә ашырыла, тәүлекнең якты вакытында җир яки су өслегеннән 150 м ким биеклектә турыдан-туры күренеш чикләрендә гамәлгә ашырыла торган, максималь очыш массасы 30 | |

| | | |
|---|---|---|
| | кг кадәр булган пилотсыз һава судноларының визуаль очышларын башкару очракларыннан тыш;<br>а) гражданнар авиациясе аэродромнарының, дәүләт һәм экспериментал авиация аэродромнары (вертодромнар) районнарының диспетчерлык зоналарыннан, тыелган зоналардан, очышларны чикләү зоналарыннан, махсус зоналардан, иҗтимагый чаралар, рәсми спорт ярышлары, шулай ук «Дәүләт сагы турында» Федераль закон нигезендә үткәрелә торган сакчылык чараларын үткәрү урыннары өстендәге һава киңлегеннән тыш;<br>б) контрольдә тотылмый торган аэродромнар һәм төшү мәйданчыкларының контроль нокталарыннан кимендә 5 км ераклыкта | |
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүче тарафыннан аларны алу юллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә оешма | Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында бирелергә тиеш:<br>1) Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә (Бердәм дәүләт юридик затлар реестрындагы мәгълүматлар Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Федераль салым хезмәте тарафыннан Бердәм дәүләт юридик затлар реестрындагы һәм Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрындагы мәгълүматларны һәм документларны бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 15 гыйнварындагы 5н номерлы приказы нигезендә салым органы тарафыннан бирелә);<br>2) Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә (Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрындагы мәгълүматлар Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Федераль салым хезмәте тарафыннан Бердәм дәүләт юридик затлар реестрындагы һәм Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрындагы мәгълүматларны һәм документларны бирү буенча | Россия Федерацясе<br>Һава кодексының 8 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 15 гыйнварындагы 5н номерлы приказы нигезендә салым органы тарафыннан бирелә);<br>3) һава транспорты (гражданнар авиациясе), Россия Федерациясе һава киңлегеннән файдалану өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтү һәм дәүләт милке белән идарә итү, функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы территориаль органының гариза бирүче тарафыннан һава киңлегеннән файдалану мөмкинлеге турында уңай бәяләмәсе (Федераль һава транспорты агентлыгының (Росавиация) Идел буе регионара территориаль һава транспорты идарәсенә запрос җибәрү юлы белән бирелә);<br>4) БДХРдан өземтә (һава судноларына теркәлгән хокуклар һәм алар белән килешүләр турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматларны үз эченә алган) («Һава судноларына хокукларны һәм алар белән килешүләрне дәүләт теркәвенә алу турында» 2009 елның 14 мартындагы 31-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бердәм дәүләт һава судноларына хокуклар һәм алар белән килешүләр реестрын алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 28 ноябрендәге 958 номерлы карары, Россия Транспорт министрлыгының «Федераль һава транспорты агентлыгының һава судноларына хокукларны һәм алар белән килешүләрне дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 6 маендагы 170 номерлы приказы нигезендә ФАВТ тарафыннан бирелә);<br>5) эксплуатантның авиация эшләрен башкаруга сертификаты (таныклыгы), аңа кушымта белән бергә/ эксплуатантның һавада коммерцияле йөртүне гамәлгә | |

| | | |
|---|---|---|
| | ашыру өчен сертификаты (таныклыгы), аңа кушымта белән бергә/эксплуатантының гомуми билгеләнештәге авиация таныклыгы, аңа кушымта белән бергә (Россия Транспорт министрлыгының «Авиация эшләрен башкаручы физик затларны, юридик затларны мәҗбүри сертификацияләүне үткәрүгә карата таләпләр. Сертификацияләүне үткәрү тәртибе» Федераль авиация кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 23 декабрендәге 249 номерлы приказы нигезендә гражданнар авиациясе өлкәсендә вәкаләтле органның территориаль органы тарафыннан бирелә).<br>Гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән документлар тапшырылмау гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый. | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган дәүләт хакимияте органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү өчен килештерү таләп ителми<br><br>Федераль һава транспорты агентлыгының (Росавиация) Идел буе регионара территориаль һава транспорты идарәсе;<br>- «Һава хәрәкәтен оештыру буенча дәүләт корпорациясе» Федераль дәүләт унитар предприятиесенең «Татаэронавигация» филиалы;<br>- Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 138 номерлы Карары нигезендә Яр Чаллы шәһәре өстендә авиация эшләрен, парашютта сикерүләрне башкарганда, бәйләп куела торган аэростатларны күтәргәндә дәүләт иминлеген тәэмин итү мөмкинлеге өлешендә). | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) документлар тиешле булмаган зат тарафыннан бирелү;<br>2) тапшырылган документлар әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәү;<br>3) гаризада һәм гаризага теркәлгән документларда аларның эчтәлегенә төшенергә мөмкинлек бирми торган алдан килештерелмәгән төзәтүләр, җитди бозулар булу;<br>4) тапшырылган документлар үз көчен югалткан;<br>5) документларны тиешле булмаган органга тапшыру | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 7 пунктчасы |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату, караусыз калдыру яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүне караусыз калдыру өчен нигезләр каралмаган.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>1) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны эшкәртү барышында Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән очракта, әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән;<br>2) Яр Чаллы шәһәре территориясе өстендә авиация эшләрен, парашютта сикерүне, бәйләп куела торган аэростатларны күтәрүне, һава судноларының демонстрацион очышларын, пилотсыз һава судноларының очышларын (максималь очыш массасы 0,25 килограммнан ким булган пилотсыз һава судноларының очышларыннан тыш), шулай ук алар хакында белешмәләр аэронавигация мәгълүматлары документларында күрсәтелмәгән Яр Чаллы шәһәре чикләрендә урнашкан мәйданчыкларга төшүне (очып китүне) килештерү нәтиҗәләре буенча, әлеге | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 9 өлеше, 14 статьясының 8 пунктчасы |

| | | |
|---|---|---|
| | Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән дәүләт органнарының тискәре бәяләмәләрен алу | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы һәм башка түләү алуның тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 9 пунктчасы |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен түләү алуның тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | - |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Чират булганда муниципаль хезмәт күрсәтүдән файдалануга гариза бирү – 45 минуттан да артык түгел.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 20 минуттан артырга тиеш түгел. | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 10 пунктчасы |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросын теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергән көннән башлап бер эш көне эчендә. | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 11 пунктчасы |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен керү мөмкинлеген тәэмин итүгә, андый | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бина һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга урнаштырыла, шул исәптән | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 12 пунктчасы,<br>1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып. Көтү залларында (бүлмәдә) мәгълүматлар, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос формалары һәм аларны тутыру үрнәкләре урнаштырыла торган стендлар.<br>Закон һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, муниципаль хезмәт күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) инвалидлар өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудыру тәэмин ителә:<br>а) объектларга тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;<br>б) муниципаль хезмәт күрсәтү урынына керү максатында объект территориясе буенча мөстәкыйль рәвештә, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүче объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаш кресло-колясkalар ярдәмендә хәрәкәт итү мөмкинлеге;<br>в) транспорт чарасына утырту һәм объектка керү алдыннан аннан төшерү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-колясkадан файдаланып һәм, кирәк булганда, объект хезмәткәрләре ярдәме белән;<br>г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны объект территориясе буенча озатып йөрү;<br>д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;<br>е) инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, объектка тоткарлыксыз керүен һәм муниципаль хезмәттән файдалануын тәэмин итү өчен кирәкле мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру, шул исәптән муниципаль хезмәттән | 15 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | файдалану өчен кирәкле ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифтында һәм контраст фонда башкарылган билгеләр белән кабатлау;<br>ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Юл күрсәтүче этне махсус укытуны раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы приказы белән расланган форма буенча һәм тәртиптә бирелгән, аның махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булганда, объектка юл күрсәтүче этнең керүен тәэмин итү.<br>Инвалидларга законда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә муниципаль хезмәтләрдән файдалану мөмкинлегенең түбәндәге шартларын булдыру тәэмин ителә:<br>а) инвалидларга, алар өчен уңайлы формада, муниципаль хезмәт күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, алар тарафыннан муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләр башкару турында мәгълүмат алу өчен кирәкле ярдәм күрсәтү;<br>б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә телен кулланып, объектка сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче керүен тәэмин итүне дә кертеп, муниципаль хезмәт күрсәтү;<br>в) инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә муниципаль хезмәттән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда башка кирәкле ярдәм күрсәтү;<br>г) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында) рельефлы-нокталы | |

| | | |
|---|---|---|
| | Брайль шрифтында һәм контраст фонда башкарылган документлар, белдерүләр, инструкцияләр, шулай ук регистратурада аудиоконтур булу. | |
| 2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем ала алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүче белән вазыйфаи затларның үзара эшчәнлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәтне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарында алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләрен кулланып | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем ала алырлык булуы түбәндәгеләр:<br>а) бинаның җәмәгать транспортына якын булган зонада урнашуы;<br>б) кирәкле сандагы белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган бүлмәләрнең булуы;<br>в) муниципаль хезмәт күрсәтүнең алымнары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүматның мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәренең мәгълүмат ресурсларында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында булуы;<br>г) инвалидларга башка затлар белән бер үк дәрәҗәдә хезмәттән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләү булмау белән характерлана:<br>а) документлар кабул иткәндә һәм гариза бирүчеләргә муниципаль хезмәт нәтиҗәләрен биргәндә чиратлар;<br>б) муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары бозылмау;<br>в) муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаятьләр;<br>г) муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтләренә шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алганда | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 13 пунктчасы |

| | | |
|---|---|---|
| | Башкарма комитет вазыйфаи затының һәм гариза бирүченең бер тапкыр үзара эшчәнлеге күздә тотыла. Үзара эшчәнлек дәвамлылыгы әлеге Регламентта билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәт КФҮдә, КФҮнең читтәге эш урыннарында күрсәтелгәндә, консультация бирү, документлар кабул итү һәм бирү КФҮ белгече тарафыннан гамәлгә ашырыла.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турындагы мәгълүматны гариза бирүче Башкарма комитетның белешмә телефоннары аша, КФҮдә алырга мөмкин. | |
| 2.16. Башка, шул исәптән муниципаль хезмәтне КФҮдә күрсәтү үзенчәлекләрен һәм муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен искә алучы таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, муниципаль хезмәт күрсәтә торган вазыйфаи зат белән гариза бирүченең бер тапкыр хезмәттәшлек итүе күздә тотыла. Хезмәттәшлек итүнең дәвамлылыгы Регламент белән билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәт дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ) күрсәтелгәндә, консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм бирүне КФҮ белгече гамәлгә ашыра. | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 4 өлешнең 1 пункты |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны КФҮдә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запросларны формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга һәм оешмаларга җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү;

6) муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документның дубликатын бирү;

7) КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша идарәгә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Идарә белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәттән файдалану өчен тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча һәм кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдаланунының башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән яки ышанычлы зат аша Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә (алга таба – эш кәгазьләрен алып бару идарәсе) яки КФҮ, КФҮнең читтәге эш урыны аша гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон формада эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә электрон почта яки Интернет-кабул итү бүлмәсе аша җибәрелә. Электрон формада кергән гаризаны теркәү хезмәт Эш регламенты белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

КФҮнең читтәге эш урыннары исемлеге регламентка 8 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.3.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризалар кабул итүче белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гариза бирүченең шәхесен аныклый;

гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен тикшерә;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булуын тикшерә;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда бозып төзәтүләр, өстәп язулар, сызган сүзләр һәм башка алдан килешенмәгән төзәтүләр булмау).

Кимчелекләр булмаган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасыннан файдаланып, гаризаны кабул итүне һәм теркәүне;

керә торган документларның теркәү карточкасын төзүне;

гариза бирүчегә, документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры турында билге куеп, гариза күчермәсен тапшыруны;

карап тикшерү өчен гаризаны һәм теркәлгән документларны бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрүне.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен, Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризаларны кабул итүче белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм аңа документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләр эчтәлеген аңлатып, гаризаны һәм документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

гаризаны һәм документларны кабул итү – 15 минут эчендә;

гаризаны теркәү – гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза яки гариза бирүчегә кире кайтарылган гариза.

3.3.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гаризаны карап тикшерә һәм гаризаны идарә башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен идарә башлыгына җибәрелгән гариза.

3.3.4. Идарә башлыгы гаризаны карап тикшерә, үтәүчене билгели һәм аны идарә белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: асылда карап тикшерү өчен идарә белгеченә җибәрелгән гариза.

3.4. Ведомствоара запросларны формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга һәм оешмаларга җибәрү

3.4.1. Идарә белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон рәвештә Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән органнар һәм оешмаларның (алга таба – мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр) бәяләмәләрен тапшыру турында, гариза бирүче тарафыннан Яр Чаллы шәһәре территориясе өстендәге һава киңлегеннән файдалану мөмкинлеге һәм билгеләнгән эш төрен үткәргәндә куркынычсызлыкны тәэмин итү мөмкинлеге турында запрос әзерли һәм җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар идарә белгеченә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән ведомствоара запрос.

3.4.2. Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрос нигезендә, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны (мәгълүматны) (алга таба – мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрнең запросларга җаваплары) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар законда билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрнең идарә белгеченә җибәрелгән запрослары.

3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Идарә белгече, мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрнең запросларга җавапларын карап тикшергәннән соң, түбәндәге карар проектларын әзерли:

- авиация эшләренең билгеләнгән төрен башкаруга рөхсәт проектын яисә

- авиация эшләренең билгеләнгән төрен башкаруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын һәм килештерү өчен идарә башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрдән запросларга җаваплар алынган вакыттан башлап ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен идарә башлыгына җибәрелгән карар проекты.

3.5.2. Идарә башлыгы авиация эшләренең билгеләнгән төрен башкаруга рөхсәт проектын карап тикшерә һәм килештерә, һәм аны имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә яисә авиация эшләренең билгеләнгән төрен башкаруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын килештерә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура карар проектын алган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән авиация эшләренең билгеләнгән төрен башкаруга рөхсәт проекты яисә имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрелгән авиация эшләренең билгеләнгән төрен башкаруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.5.3. Башкарма комитет Җитәкчесе авиация эшләренең билгеләнгән төрен башкаруга рөхсәт проектын имзалый һәм теркәү өчен идарәгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм теркәү өчен идарәгә җибәрелгән авиация эшләренең билгеләнгән төрен башкаруга рөхсәт проекты.

3.5.4 Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары авиация эшләренең билгеләнгән төрен башкаруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын имзалый һәм аны теркәү өчен идарәгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм теркәү өчен идарәгә җибәрелгән авиация эшләренең билгеләнгән төрен башкаруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты.

3.5.5. Идарә белгече имзаланган карар проектын теркәүне гамәлгә ашыра (алга таба – муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе):

1) бирелгән рөхсәтләрне исәпкә алу журналында авиация эшләренең билгеләнгән төрен башкаруга рөхсәт (Регламентка 6 нчы кушымта);

2) авиация эшләренең билгеләнгән төрләрен башкаруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе (Регламентка 7 нче кушымта).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура идарә белгеченә имзаланган карар проекты кергән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе.

3.6. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү

3.6.1. Идарә белгече, гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, гариза бирүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында белдерә, аны бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

3.6.2. Идарә белгече гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирә (җибәрә).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гамәлгә ашырыла:

- 15 минут эчендә – гариза бирүче (аның вәкаләтле вәкиле) шәхсән килгән очракта;

- алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә –муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе почта аша җибәрелгән очракта.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән (җибәрелгән) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе.

3.7. Муниципаль хезмәтне КФҮ аша күрсәтү

3.7.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮгә, КФҮнең читтәге эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.7.2. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү КФҮнең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.7.3. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮдән документлар кергәндә, процедуралар Регламентның 3.3 – 3.6 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.

3.8. Техник хаталарны төзәтү

3.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә яисә КФҮгә, КФҮнең читтәге эш урынына түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (Регламентка 4 нче кушымта);

гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ;

техник хаталар булуны раслаучы юридик көчкә ия документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документта күрсәтелгән мәгълүматлардагы техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүченең (вәкаләтле вәкиленең) шәхсән үзе тарафыннан яки почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып); яисә Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы; яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы; КФҮ, КФҮнең читтәге эш урыны аша бирелә.

3.8.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең документлар кабул итү өчен җаваплы белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итүне, теркәүне гамәлгә ашыра һәм аларны идарәгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура техник хатаны төзәтү турында гариза теркәлгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен идарә белгеченә җибәрелгән техник хатаны төзәтү турында гариза.

3.8.3. Идарә белгече гаризаны һәм документларны карап тикшерә, Регламентның 3.5 – 3.6 пунктларында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм, техник хаталы документның төп нөсхәсен гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алып һәм имза куйдырып, төзәтелгән документны – муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен шәхсән гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә яки техник хаталы документның – муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең төп нөсхәсен идарәгә тапшырганда документны алу мөмкинлеге турындагы хатны гариза бирүчегә почта аша (электрон почта аша) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура техник хатаны төзәтү турында гариза теркәлгәннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: төзәтелгән һәм гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе.

3.8.4. Җибәрелгән техник хаталарны төзәтүдән баш тарту өчен нигезләр.

- техник хатаны төзәтү турында гариза тиешле булмаган зат тарафыннан бирелү;
- документларны тиешле булмаган органга бирү.

3.9. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документның дубликатын (алга таба – дубликат) бирү.

3.9.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документ югалган (бозылган) очракта, гариза бирүче Башкарма комитетка әлеге документның дубликатын бирү турында гариза (регламентка 5 нче кушымта) бирә.

Дубликат бирү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк аша бирелә.

3.9.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч дубликат бирү турында гаризаны кабул итә, теркәлгән документлары белән гаризаны терки һәм аларны идарәгә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карауп тикшерү өчен идарә белгеченә җибәрелгән гариза.

3.9.3. Идарә белгече документларны карап тикшерә һәм, нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документның идарәдә булган икенче нөсхәсе нигезендә дубликат әзерли. Билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән документ проектын килештерә.

Баш тарткан очракта баш тарту турында хат проекты әзерли. Дубликат бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

- гариза гариза бирүченең мәнфәгатьләрен яклау вәкаләте булмаган зат тарафыннан бирелгән;

- гариза бирүче элек муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итмәгән;

- гариза бирүченең инициативасы буенча гаризаны кире алу.

Идарә белгече гариза бирүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, рәсмиләштерелгән дубликатны яки аны бирүдән баш тарту турында хатны бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә.

